| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**29.12.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 53** |

«Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медален гамәлгә кертү турында

Гражданнарны һәм иҗтимагый оешмалар коллективларын махсус хәрби операциядә катнашучыларга күрсәткән ярдәмнәре өчен бүләкләү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1.«Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медален гамәлгә кертергә.

2. «Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медале турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (htpp:/pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында халыкка җиткерергә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы ,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

«Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медале турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. «Махсус хәрби операциягә ярдәм иткән өчен» медале (алга таба — Медаль) Зеленодольск муниципаль районы гражданнарын, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) коллективларын һәм предприятиеләрен җәмәгатьчелек тарафыннан тану һәм бүләкләү формасы булып тора:

- махсус хәрби операциядә (алга таба – МХО) катнашучыларга гуманитар, техник ярдәм җыюны оештырган һәм күрсәткән өчен;
- МХО зонасына йөкләр китергән, озата барган өчен;
- МХО ихтыяҗлары өчен кирәкле әйберләр җитештерүне оештыру һәм актив эшчәнлек өчен.

1.2. Кандидатларның үтенечнамәләрен һәм документларын бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау буенча Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан төзелгән һәм расланган Комиссия (алга таба – Комиссия) карый.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә каралган чыгымнар Зеленодольск муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

2 нче статья. Медальнең сурәте һәм тасвирламасы

2.1. Медальнең сурәте һәм тасвирламасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан әзерләнә һәм Комиссиягә тәкъдим ителә.

2.2. Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тапшырган медальнең сурәтен һәм тасвирламасын карый һәм килештерә.

2.3. Медальнең сурәте һәм тасвирламасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

3 нче статья. Медаль белән бүләкләү тәртибе

3.1. Медаль белән бүләкләү әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла.

3.2. Медаль белән бүләкләү турындагы үтенечнамә белән Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре, иҗтимагый оешмалары (берләшмәләре) һәм учреждениеләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы Хәрби комиссариаты, Зеленодольск муниципаль районы һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнары чыгыш ясый.

3.3. Гражданнарның әлеге Нигезләмәнең 1.1 пунктында күрсәтелгән категорияләргә карата мөнәсәбәтен раслый троган конкрет казанышларын тасвирлап медаль белән бүләкләү үтенечнамәсе һәм «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы исеменә җибәрелә.

3.4. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән бүләкләү документлары каралмый һәм җибәрелгән бозуларны аңлатып һәм аларны бетерү тәкъдиме белән инициаторга кире кайтарыла.

3.5. Комиссия бүләкләү документларын тапшырылган көннән алып бер ай эчендә карый. Медаль белән бүләкләү турындагы үтенечнамә кире кагылган

очракта, Комиссия үтенечнамә инициаторына әлеге карарның мотивларын Комиссия карар кабул иткән көннән алып бер ай эчендә хәбәр итә.

3.6. Медальләргә заказ бирү һәм аларны исәпкә алу Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан алып барыла.

## 4 нче статья. Медаль белән бүләкләүне рәсмиләштерү тәртибе

4.1. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге Комиссия утырышына документлар әзерли.

4.2. Тәкъдим ителгән документлар һәм Комиссия нәтиҗәләре нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан медаль белән бүләкләү турында карар кабул ителә.

4.3. Медаль белән бүләкләү турында карар Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында игълан ителә.

4.4. Бүләкләнгән затка медаль һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклык тапшырыла.

4.5. Медаль һәм таныклыкны тапшыру Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан тантаналы шартларда башкарыла.

4.6. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы кушуы буенча һәм аның исеменнән медальне түбәндәгеләр тапшыра ала:

- Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары;
- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары;
- Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе;
- Зеленодольск муниципаль районы составына кергән авыл җирлекләре башкарма комитетлары башлыклары, җитәкчеләре, җитәкчеләр урынбасарлары,секретарьлары.

4.7. Исән чагында медаль бирелмәгән бүләкләнүче вафат булган очракта, бүләк бүләкләнүченең саклау өчен гаиләсенә тапшырыла.

4.8. Медаль югалган очракта аның дубликаты бирелми.

4.9. Медаль белән кабат бүләкләү рөхсәт ителми.

4.10. Бүләкләнүчеләрне исәпкә алу Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан башкарыла.

## 5 нче статья. Бүләкләү турында карарларны гамәлдән чыгару, медальсез калдырылу

5.1.Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы, бүләкләүдән соң бүләкләүгә тәкъдимнең дөрес булмавы яисә нигезсез булуы ачыкланган очракта, медаль белән бүләкләү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга хокуклы.

5.2. Медаль белән бүләкләүне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән затка карата тапшырылган медаль Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлегенә кайтарылырга тиеш.

Нигезләмәгә
1 нче кушымта

Мин,

________________________________________________________________________,

фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны,

шәхесне таныклаучы документ: ________________________________

(документ төре, серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

________________________________________________________________

Зеленодольск муниципаль районы Советының вәкаләтле вазыйфаи затларына, Бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау комиссиясенә бүләкләүгә тәкъдим ителгән минем шәхси мәгълүматларымны (автоматлаштырудан файдаланып яисә шәхси белешмәләре булган мондый чараларны кулланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәлгә (операциягә) яисә гамәлләргә (операцияләргә) барсына бергә, җыюны, язып алуны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне) тапшыруны (таратуны, бирүне, керүне), шәхессезләндерүне, блоклауны, бетерүне, юк итүне) кертеп, бүләкләүгә тәкъдим ителгән минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ихтыярый ризалыгымны бирәм:

- фамилия, исем, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, гражданлык;

- Россия Федерациясе гражданы паспорты (сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән).

Биометрик шәхси мәгълүматлар:

- фотографик сурәт.

Мин түбәндәгеләр белән таныштым:

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык имзалау датасыннан башлап ________________ елга кадәр гамәлдә;

- ризалык ирекле формада язмача гариза нигезендә кире алынырга мөмкин.

________________________ ____________________

(имза) (дата)